| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МАТАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Матак авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 марты №40/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл жирлеге Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиялән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен Эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге муниципаль хокукый актларны «Гражданнарның үз ихтыяжлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында (2018 елның 3 августына үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл жирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2017 нче елның 28 июлендә Татарстан республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл жирлеге Советы карары нигезендә расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл жирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан, коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен Эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмә" нең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары " сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Матак авыл җирлеге башлыгы: В.М.Михайлов